ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 октябрь, 2023 ел № 27/6

Шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы Карары белән кабул ителгән акцияләрнең йөз проценты (өлеше) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 145 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 28 статьясындагы 52 пункты

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы Карары белән кабул ителгән акцияләрнең йөз проценты (өлеше) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмәнең (Шәһәр Советының 2023 елның 29 июнендәге 25/6 номерлы Карары редакциясендә) 8 пунктының 2 пунктчасындагы 2 таблицасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2 багана исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Оешмалар эшчәнлеге төре»;

2) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Тамаша-күңел ачу эшчәнлеген алып баручы оешмалар | 200 кадәр | 5 |
| | | 201 дән 250 кадәр | 5,5 |
| | | 251 дән 300 кадәр | 6 |
| | | 301 дән 350 кадәр | 6,5 |
| | | 351 дән 400 кадәр | 7 |
| | | 401 һәм аннан артыграк | 7,5.». |

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев